**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының**
**Олы Әтнә авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

22 июнь 2026 ел №20

**Олы Әтнә авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

2025 елның 29 декабрендәге 567-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында», 2024 елның 12 декабрендәге 540-ФЗ номерлы Федераль законнар, Татарстан Республикасы Әтнә районы прокурорының 02-08-02-2026/Прдп215-26 номеры 2026 елның 28 апрелендәге протесты нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Олы Әтнә авыл җирлеге Советы карар итте:

1. «Олы Әтнә авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Советының 2021 елның 23 декабрендәге 37 номерлы карары белән расланган Олы Әтнә авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы нигезләмәгә (18.01.2024 N 91, 12.05.2025 № 113 , 06.02.2026 №11 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

**1.1. Нигезләмәнең 3.3.3 пунктында** “кисәтүгә карата» сүзләреннән соң «,шул исәптән бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яисә региональ дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша» сүзләрен өстәргә.;

**1.2. Нигезләмәнең 3 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле «3.6.10.», «3.7 - 3.7.10.» пунктлары өстәргә:**

«3.6.10. Мәҗбүри профилактик визит контрольдә тотылучы затның аны үткәрүдән баш тартуын күздә тотмый. Контрольдәге затка мәҗбүри профилактик визит уздыру турында ул башланырга егерме дүрт сәгатьтән дә соңга калмыйча «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында»Федераль законның 21 статьясындагы 5 өлешендә каралган тәртиптә хәбәр ителә.”

3.7. Контрольдәге зат инициативасы буенча профилактик визит.

3.7.1. Контрольдәге зат инициативасы буенча профилактик визит, әгәр мондый зат кече эшмәкәрлек субъектларына караган булса, социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма йә дәүләт яисә муниципаль учреждение булса, аның гаризасы буенча үткәрелергә мөмкин.

3.7.2. Контрольдәге зат профилактик визит уздыру турында гаризаны бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яисә региональ дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшыра. Контроль орган гаризаны ун эш көне дәвамында карый һәм профилактик визит үткәрү турында йә аны уздырудан баш тарту турында карар кабул итә, бу хакта контрольдә тотылучы затка хәбәр итә.

3.7.3. Профилактик визит үткәрү турында карар кабул ителгән очракта, контроль органы егерме эш көне эчендә аны үткәрү датасын контрольдә тотылучы зат белән мондый килештерүне теркәүне тәэмин итә торган теләсә нинди ысул белән килештерә.

3.7.4. Профилактик визит үткәрүдән баш тарту турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) контрольдә тотыла торган заттан гаризаны кире алу турында хәбәр алынса;

2) кабат гариза бирү датасына кадәр алты ай дәвамында профилактик визит уздыру контрольдә тотылучы затның эшчәнлек башкару урынында булмавы йә контрольдә

тотылучы затның профилактик визит уздыру мөмкин булмавына китергән башка гамәлләре (гамәл кылмавы) сәбәпле мөмкин булмаса;

3) гариза бирү датасына кадәр ел дәвамында контроль орган элегрәк бирелгән гариза буенча профилактик визит уздырса;

4) гаризада цензурасыз яки мыскыллаучы сүзләр, контроль органы вазыйфаи затларының йә аларның гаилә әгъзаларының гомеренә, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янаулар булса;

5) контрольдә тотылучы зат 3.7.1 пунктында каралган критерийларга туры килмәсә.

3.7.5. Профилактик визит үткәрүдән баш тарту турындагы ккарарга «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль законда билгеләнгән тәртиптә контрольдә тотылучы зат тарафыннан шикаять белдерелергә мөмкин.

3.7.6. Контрольдә тотылучы зат гаризаны кире алырга йә профилактик визитны үткәрүдән баш тартырга хокуклы, бу хакта контроль органга аны үткәрү датасына кадәр биш эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә хокуклы.

3.7.7. Профилактик визит кысаларында контрольдә тотылучы затның ризалыгы белән инспектор пробалар (үрнәкләр) сайлап ала, инструменталь тикшерү, сынау үткәрә.

3.7.8. Профилактик визит барышында контрольдә булган зат тарафыннан алынган аңлатмалар һәм тәкъдимнәр рекомендация характерында була.

3.7.9. Тикшерү барышында ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәләр контрольдә тотыла торган затларга бирелә алмый.

3.7.10. Профилактик визит үткәргәндә контроль объектларының закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычы тудыруы яисә мондый зыян китерелүе ачыкланган очракта, инспектор бу хакта контроль чаралар үткәрү турында Карар кабул итү өчен контроль органның вәкаләтле вазыйфаи затына кичекмәстән мәгълүмат җибәрә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru. адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Олы Әтнә авыл җирлеге башлыгы: Хисамиев Р.Ш.